**Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы**

**Аграмак авыл җирлеге башкарма комитеты**

**КАРАР**

**№ 13** **09.04.2019 ел.**

**“Аграмак авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 9 гыйнварында кабул ителгән “Аграмак авыл җирлегендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру” нигезләмәсен раслау турында” карарга үзгәрешләр кертү турында”**

"Аграмак авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында” нигезләмәне гамәлдәге законнарга яраклаштыру ниятендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Аграмак авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАРЫ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Башкарма комитетының «Аграмак авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында” нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:
3.2, 3.8 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“3.2. Гражданнарның яшәү яисә вакытлыча(3 айдан артык вакыт) тору урыннарында, яки альтернатив граждан хезмәте үтү урынында гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашырырга.
3.8. хәрби комиссариатка ел саен 1 октябрьгә кадәр 15 яшькә җиткән ир-атлар һәм 16 яшькә җиткән ир-атлар, ә 1 ноябрьгә кадәр- киләсе елда хәрби исәпкә куелырга тиешле ир-атлар исемлеген тәкъдим итәргә”.
2.Әлеге карарны Аграмак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Спас муниципаль районының http:/ www. spassriy.tatarstan.ru рәсми сайтының Аграмак авыл җирлеге битендә һәм хокукый мәгълүмати сайтта (///http:pravo.tatarstan.ru) законда билгеләнгән срокта урнаштырырга.
3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Спас муниципаль районы Аграмак авыл
җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе: Р.Т.Галәветдинова